ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» июнь 2020 ел № 172

Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлеген
сату буенча ачык аукцион уздыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Торак пункт җирләре составыннан җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрергә һәм җир кишәрлеген аукционга чыгарырга.
2. Аукцион комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).
3. Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен (“аукцион адымын”) расларга (2 нче кушымта).
4. Аукционны уздыру һәм аның нәтиҗәләре турында «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында хәбәр итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм сату турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (https://torgi.gov.ru) җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында хәбәр урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Р. Вәлиев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
05.06.2020 ел, № 172
карарына 1 нче кушымта

**Аукцион комиссиясе составы**

1. Вәлиев Азат Рөстәмович – **комиссия рәисе**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы;

2. Поносов Эдуард Александрович – **комиссия рәисе урынбасары**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килештерү буенча);

**Комиссия әгъзалары:**

3. Лукшин Павел Алексеевич – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының контроль һәм исәп бүлеге башлыгы (килештерү буенча);

4. Андреева Ирина Евгеньевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе урынбасары (килештерү буенча);

5. Вәлиев Руслан Рамилевич – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килештерү буенча).

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
05.06.2020 ел, № 172
карарына 2 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеге, бәяләү бәясе күләме, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләме («Аукцион адымы»)**

| № | Урнашу урыны, мәйданы, җир кишәрлегенең кадастр номеры, аукцион үткәрү өчен нигез, капиталь төзелеш объектының максималь һәм (яки) минималь рөхсәт ителгән параметрлары, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыру )техник шартлары һәм аларның гамәлдә булу вакыты, тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү турында мәгълүмат | Рөхсәт ителгән куллану | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум. | Аукцион адымы (Башлангыч бәядән 3%), сум | Беренчел кертем (Башлангыч бәядән 20%), сум |
|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** |
| 1 | ТР, Әгерҗе районы, Әгерҗе ш, Казанская ур., ж/к 71<br>Мәйданы – 590кв.м<br>Кадастр номеры - 16:01:220294:188 | Кибет урнаштыру өчен | 288000 | 8640 | 57600 |